# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында" Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында" 2008 елның 2 августындагы 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 8 (I өлеш); 2009, № 6; 2011, № 5, № 11 (I өлеш), "10" санын "50" санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган һәм оешмалар табышына салым буенча чираттагы салым чоры аеның беренче числосыннан иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 29 ноябре
№ 79-ТРЗ